**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Глава**
**Балтачевского сельского**
**поселения» Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Молодежная, д 1а , с. Балтачево
Азнакаевского муниципального района
423302, Тел. (8-292) 4-47-23

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**«Балтач авылы жирлеге**
**Советы башлыгы**

Азнакай муниципаль районы, Балтач авылы,
Яшьлэр урамы, 1а
423302, Тел. (8-292) 4-47-23

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» октябрь 2025 ел № 4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Балтач авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең Балтач торак пунктында, Балтач авылында теркәлгән йортлар буенча сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Халык җыенының 2025 елның 7 ноябрендэ 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2.Билгеләү:

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач авыл җирлегендә үзара салым кертү буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитеты.;

- гражданнар Җыенын уздыру вакыты-2025 елның 7 ноябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

3.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2025 елның 27 октябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга Балтач авылы, Молодежная урамы, 1А йорт адресы буенча бирергә.;

- Балтач торак пунктында яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия исемлекләрен төзергә;.;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

- Балтач торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.
4.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Сез, 2026 елда 1 төркем инвалидлар, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм анын семья әгъзаләре,көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар, Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Балтач торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзу,ремонтлау,карап тоту( Узәк ,Яшьләр ,А.Алиш,8 Март урамнарына вак таш сатып алу,төяу,ташу,салу).
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (юлларны һәм территорияләрне кардан чистарту)

« РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru бүген Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru) һәм Балтач авылы,Молодежная ур., 1А йорт,Центральная ур., 37 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында.
6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Рәис  Л.Л.Хәбипов